**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «17» сентябреннән № 205

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен билгеләү турында» 2025 елның 04 июлендәге 150 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы иҗтимагый торак комиссиясе нигезләмәсен һәм составын раслау турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 февралендәге 49 номерлы карары, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының 2025 елның 07 февралендәге 56 номерлы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик

күрсәткечләрен билгеләү турында» 2025 елның 04 июлендәге 150 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен - 30956,25 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 30956,25 сум;

1.2.3. өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 30956,25 сум».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (инфраструктур үсеш буенча) йөкләргә.

Җитәкче Е.А. Тарнавский